# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Алабуга» ирекле икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Алабуга» ирекле икътисадый зонасы турында» 1998 елның 22 апрелендәге 1569 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 5; 1999, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 статьяда:

өченче абзацта «Алабуга» ирекле икътисадый зонасы инфраструктурасы» сүзләрен «Ирекле икътисадый зонаның инфраструктурасы» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонада катнашучылар - Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында Ирекле икътисадый зона администрациясе белән шартнамәләр төзегән һәм Ирекле икътисадый зонада катнашучылар реестрына кертелгән юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны үз эченә алучы салым түләүчеләр категориясе.».

2. 2 статьяда:

беренче өлештә «Алабуга» сүзен төшереп калдырырга;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонада Ирекле икътисадый зонада катнашучылар буларак теркәлгән юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга бирелүче

инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлегенең махсус ташламалы режимы билгеләнә.».

3. 6 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зона администрациясенең икътисадый программаларын финанслау һәм Ирекле икътисадый зона администрациясе эшчәнлеген матди-техник яктан тәэмин итү Ирекле икътисадый зонаны үстерү фонды акчалары исәбеннән башкарыла.»;

өченче өлешнең икенче абзацын төшереп калдырырга.

4.7 статьяда:

икенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Ирекле икътисадый зонаның инфраструктурасыннан файдаланган очен читкә чыгарылучы товарларның (өстәлгән бәягә салымны исәпләмичә), Ирекле икътисадый зона территориясендә күрсәтелгән хезмәтләрнең (өстәлгән бәягә салымны исәпләмичә) һәм Ирекле икътисадый зона территориясендә башкарылган эшләрнең (өстәлгән бәягә салымны исәпләмичә) хакыннан Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан билгеләнә торган ике процентка кадәр күләмдә;»;

өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләрен арендалаган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе, аренда түләвен кертү тәртибе, шартлары һәм вакытлары, гамәлдәге законнарны, инвестиция проекты үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Аренда түләве күләме Ирекле икътисадый зонада катнашучы белән Ирекле икътисадый зона администрациясе арасында төзелүче шартнамәдә каралган тәртип нигезендә билгеләнә.»;

җиденче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«АлАЗ-ДМ" Корпорациясе, янга калган акчаларны куәтләр булдыруга һәм җиңел автомобильләр җитештерүне оештыруга юнәлткән очракта, Ирекле икътисадый зона инфраструктурасыннан файдаланган өчен 2005 елга кадәр Ирекле икътисадый зонаны үстерү фондына түләүләрдән азат ителә.».

5. 8 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонада катнашучылар, бердәй социаль салым һәм физик затларның керемнәренә салым буенча түләүләрдән гайре, Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләреннән һәм җыемнардан, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләүләрдән законнар нигезендә азат ителәләр.».

6.10 статьяда:

өченче өлештә:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның гаризаларын карау һәм әлеге проектларны үтәү турында, алар белән шартнамәләр төзү, аларны Ирекле икътисадый зонада катнашучылар реестрына кертү;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонада катнашучыларның алган йөкләмәләрен үтәүләрен тикшереп тору, шул исәптән Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында шартнамәләрне өзү, аларны Ирекле икътисадый зонада катнашучылар реестрыннан төшереп калдыру;»;

дүртенче өлештә «шулай ук юкка чыгарылган реестрлар һәм яңадан торгызылган Рөхсәтләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

7.13 статьяның текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зона администрациясе әлеге Закон нигезендә Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның гаризаларын карый һәм, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәгән килеш, әлеге проектларны гамәлгә ашыру турында алар белән шартнамәләр төзи. Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзелгән мизгелдән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар Ирекле икътисадый зонада катнашучы статусын алалар.

Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында гаризалар карау һәм әлеге проектларны гамәлгә ашыру турында шартнамәләр төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Ирекле икътисадый зона администрациясе Ирекле икътисадый зонада катнашучылар реестрын Ирекле икътисадый зона территориясендә

инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында шартнамәләр төзү нигезендә алып бара.

Ирекле икътисадый зонада катнашучы үзенә алган йөкләмәләрен үтәмәгәндә, Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә өзелә һәм ул Ирекле икътисадый зонада катнашучылар реестрыннан төшереп калдырыла.».

8.16 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонага керү, Ирекле икътисадый зонадан чыгу һәм аның территориясендә булу тәртибе Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.».

9.18 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыру буенча үзләренә алган йөкләмәләрен шартнамә нигезендә үтәүче Ирекле икътисадый зонада катнашучыларга әлеге статьяның «б » һәм «в » пунктларында күрсәтелгән очракларда, әгәр Ирекле икътисадый зонаны бетерү турында карар кабул итү көненә Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамәнең гамәлдә булу вакыты узмаган булса, китерелгән зыян законнар нигезендә түләтелә.».

10.19 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле икътисадый зонада катнашучылар милкен национализацияләү яисә реквизицияләү очрагында компенсация түләвенең күләме, шартлары яисә тәртибе мәсьәләләре буенча бәхәсләр, әгәр Россия Федерациясенен халыкара шартнамәләрендә бәхәсләрне карауның бүтән тәртибе каралмаган булса, законнар нигезендә карала.».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 17 гыйнвары
№ 1281